**МИНИСТЕРСТВО ЭКОЛОГИИ И ПРИРОДНЫХ РЕСУРСОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЭКОЛОГИЯ ҺӘМ ТАБИГАТЬ РЕСУРСЛАРЫ МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** Казан ш. **БОЕРЫК**

25.12.2024 1437-п

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районында урнашкан Крутайка, Чирка (Черка) елгаларының су саклау зоналарын һәм яр буе саклык полосаларын билгеләү турында

Россия Федерациясе Су кодексы, «Күчемсез милекне дәүләт теркәвенә алу турында» 2015 елның 13 июлендәге 218-ФЗ номерлы федераль законның 32 статьясы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2009 елның 10 гыйнварындагы 17 номерлы карары белән расланган Су саклау зоналары чикләрен һәм су объектларының яр буе саклык полосалары чикләрен билгеләү кагыйдәләре, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы мәсьәләләре» 2005 елның 6 июлендәге 325 номерлы карары нигезендә һәм «Татарстан Республикасы Буа муниципаль районында урнашкан Крутайка, Чирка (Черка) елгаларының су саклау зоналарын һәм яр буе саклык полосаларын билгеләү» 2024 елның 2 маендагы 2024.003 номерлы контракт кысаларында башкарылган эшләр нәтиҗәләре буенча боерык бирәм:

1. Россия Федерациясе Су кодексының 65 статьясы нигезендә, әлеге чикләрдә хуҗалык һәм башка төр эшчәнлекне гамәлгә ашыруның махсус режимын исәпкә алып, Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан су объектларының су саклау зоналары һәм яр буе саклык сызыклары киңлеген билгеләргә:

1.1. Крутайка елгасы:

су саклау зонасының киңлеге – 50 м;

яр буе саклык полосасының киңлеге – 50 м.

1.2. Чирка (Черка) елгасы:

су саклау зонасының киңлеге – 100 м;

яр буе саклык полосасының киңлеге – 50 м.

2. Су объектларын саклау бүлегенә (В.А.Долгов):

2.1. Крутайка, Чирка (Черка) елгаларының су саклау зоналары чикләре һәм яр буе саклык полосалары чикләре турында белешмәләрне дәүләт су реестрына кертү өчен Су ресурслары федераль агентлыгына җибәрергә;

2.2. су саклау зоналары һәм яр буе саклык полосалары чикләре билгеләнгән территорияләргә карата муниципаль, шәһәр округы, торак пунктлар җирле үзидарә органына мәгълүмат җибәрергә;

2.3. Крутайка, Чирка (Черка) елгаларының су саклау зоналары чикләре һәм яр буе саклык полосалары чикләре турында мәгълүматны Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрындагы мәгълүматларга үзгәрешләр кертү өчен Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенә (аның территориаль органына) җибәрергә.

3. Экологик куркынычсызлыкны тәэмин итү өлкәсендәге проектларны пропагандалау бүлегенә (Е.В. Веселова) әлеге боерыкны татар теленә тәрҗемә итәргә.

4. Хокукый тәэминат бүлегенә (Р.А.Заһидуллин) әлеге боерыкны, теркәтү өчен, Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрүне тәэмин итәргә.

5. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тотуны министр урынбасары О.В.Манидичевага йөкләргә.

Министр А.В. Шадриков